СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

12 марта 2021 года | № 23

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Кунып авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Кунып авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кунып авыл җирлеге Советының 21.10.2019 елның 130 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Кунып авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.7 пунктны (кемнэрдер 1.6 пунктны) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә»;

2. 1.7 пунктның (кемнэрдер 1.6 пунктның) 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа оешкан җирлекне булдыру турында, шулай ук яңа оешкан җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән дә артмаган булса, яңа оешкан җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;»;

3. 3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Гражданнар җыены, анда торак пунктның яки җирлекнең сайлау хокукына ия халкының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы санала. Әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан күбрәге бер үк вакытта торак пунктта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены

гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы риза дип тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.»;

4. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы Р.О.Егоров